1нче марттан 7 нче мартка кадәр МББО “187 нче номерлы күп профильле лицей”да тарих  Һәм җәмгыят белеме укытучыларның методик атналыгы булып узды. Әлеге чараны “Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге” елына багышладылар. Атна дәверендә укучылар белән ачык дәресләр, дәрестән тыш чаралар, китапханәдә фәнни һәм әдәби китаплар күргәзмәсе булып узды.

4нче мартта яшь укытучы Файзуллин Динар Ринатович 7 нче Б сыйныфы белән “Рәсәйнең дәүләт символлары” дигән темага лицейның укытучыларына ачык дәрес күрсәтте.

3нче март көнне тәҗрибәле тарих укытучысы Квитко Мария Владимировна 5 нче А сыйныфы укучылары белән “Элеккеге олимпия уеннары” дигән темага зирәкле викторина оештырды. Укучылар бик рәхәтләнеп шул чорга караган олимпия уеннарының килеп чыгышы, аларның тарихы һәм төрләре белән таныштылар, һәм актив рәвештә сорауларга җавап кайтара тордылар.

5нче мартта тарих укытучысы Файзуллина Альбина Маликовна  5нче Г сыйныфы укучылары белән “Борынгы Грециянең мифлар белгече” дип аталган интерактив сәяхәттә булдылар. Бу дәрестән тыш чара да бик кызыклы булды. Укучылар шул чор персонажларын сурәтләделәр, ошаган мифның бер өзегенә инсценировка да күрсәттеләр. Гомумән, тарихчылар атналыгы укучылар өчен бик файдалы булды, алар үзләре өчен бик мәгълүмат алдылар. Киләчәктә барысына да уңышлар телибез!




2021


2021


2021